МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.10.2018 г.Казань № 497

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидия рәвешендә дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча конкурста сайлап алуга кертелгәннәр исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының «Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидия рәвешендә дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча конкурста сайлап алуга кертелгәннәр исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерык аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»;

боерыкның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга

кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга»;

Боерык белән расланган Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидия рәвешендә дәүләт ярдәмен күрсәтү буенча конкурста сайлап алуга кертелгәннәр исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә (теркәлә) бәян итәргә.

2. Конкуренция һәм эшкуарлык үсешен анализлау бүлегенә әлеге боерыкның законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлек бүлегенә әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары – Эшкуарлыкны үстерү департаменты директоры Р.Р. Сибгатуллинга йөкләргә.

**Министр** **Ф.С. Габделганиев**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 едның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 16.10.2018 № 497 боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – административ регламент) Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар булып мөрәҗәгать итүчеләр – «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән шартларга ярашлы рәвештә кече предприятиеләргә, шул исәптән микропредприятиеләргә, һәм урта предприятиеләргә кертелгән, алар турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән хуҗалык итүче субъектлар (юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар);

1.3. Дәүләт хезмәте «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – учреждение) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Учреждение урнашкан урын: 420021, Россия, Татарстан Республикасы, Казан ш., Мәскәү ур., 55;

учреждениенең эш графигы:
дүшәмбе-пәнҗешәмбе – 9.00 - 18.00;
җомга – 9.00 - 16.45;
шимбә, якшәмбе – ял көннәре;
төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Гаризалар кабул итү графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе – 9.00 - 18.00 (гаризалар кабул итү чорында);

җомга – 9.00 - 16.45 (гаризалар кабул итү чорында);

шимбә, якшәмбе – ял көннәре;

төшке аш 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Кертү рөхсәт кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Учреждениенең белешмә телефоны: 8 (843) 236-29-96.

1.3.3. Учреждениенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты юк. Учреждениенең электрон почта адресы: crppmsp.rt@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша:

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (http://chistopol.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (http://www.e-nkama.ru/), «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты» (http://nabchelny.ru/), «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (http://mendeleevsk.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы башкарма комитеты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru/), Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты (http://городелабуга.рф/) рәсми сайтларында (алга таба – рәсми сайт);

Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Портал);

2) учреждениегә телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

3)учреждениегә язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә;

4) учреждение бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Административ регламентның 1.1, 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 209-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 31, 4006, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Российская газета, 2010, 30 июль, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Бухгалтерлык исәбе турында» 2011 елның 06 декабрендәге 402-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 402-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый

мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2011, 7 декабрь, бастырып чыгару номеры: 0001201112070017, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Узган календарь елы өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлек исәбе турында белешмәләр рәвешен раслау турында» 2007 елның 29 мартындагы ММ-3-25/174@ номерлы боерыгы (алга таба – ММ-3-25/174@ номерлы РФ ФСХ боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, № 19, 07.05.2007);

Россия Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыен түләүченең, иминият кертемнәре түләүченең, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәве турында белешмә рәвешен, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматын раслау турында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы (алга таба – ММВ-7-8/20@ номерлы Россия ФСХ боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы);

Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең «Иминиятләштерелгән затлар турында белешмәләр» рәвешен раслау турында» 2016 елның 01 февралендәге 83п номерлы карары (алга таба – РФ ПФ Идарәсенең 83п номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 880 номерлы карары белән расланган Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы төзү һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү чараларының нәтиҗәлелеген мониторинглау турында» 2016 елның 01 августындагы 530 номерлы карары (алга таба – 530 номерлы ТР МК карары)

(Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.08.2016, № 12, 0371 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү буенча Татарстан Республикасы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 12 маендагы 319 номерлы карары (алга таба – 319 номерлы карар) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Яшел Үзән шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карары (алга таба – 1331 номерлы карар) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Чистай шәһәре Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 18 маендагы 100 номерлы карары (алга таба – 100 номерлы карар)(Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү буенча Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәрендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2017 елның 24 маендагы 584 номерлы карары (алга таба – 584 номерлы карар) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Яр Чаллы моношәһәренең җайланмага лизингны һәм социаль эшкуарлыкны үстерү чаралары кысаларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу һәм субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү тәртибе турында» 2017 елның 24 маендагы 3178 номерлы карары (алга таба – 3178 номерлы карар)(Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтү буенча «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларын сайлап алу тәртибе турында» 2017 елның 31 маендагы 331 номерлы карары (алга таба – 331 номерлы карар)(Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче учреждение тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән

белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

гариза – дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә (әлеге административ регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән бланкта тутырыла) (алга таба – заявка);

мәгълүмат системасы – Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдщм күрсәтүгә вәкаләтле оешмаларның эшчәнлеген автоматлаштыруга, шулай ук ведомствоара багланышларда катнашу процессларында мәгълүмат белән булышуга юнәлдерелгән «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасы;

гади электрон имза – ул кодлар, парольләр яки башка төрле чаралар куллану юлы белән билгеле бер зат тарафыннан электрон имза формалаштырылуын раслый торган электрон имза;

электрон имза – электрон формадагы башка мәгълүматка (имзалан торган мәгълүматка) тоташтырылган яки мондый мәгълүмат белән башкача бәйләнгән һәм мәгълүматны имзалаучы затны ачыклау өчен кулланыла торган электрон формадагы мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләп билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау. | 584 номерлы карарның 5.3 п; 1331 номерлы карарның 5.3 п.; 331 номерлы карарның 5.3 п.; 3178 номерлы карарның 20 п.; 319 номерлы карарның 5.3 п.; 100 номерлы карарның 5.3 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе | 584 номерлы карарның 1.5 п; 1331 номерлы карарның 1.5 п.; 331 номерлы карарның 1.5 п.; 3178 номерлы карарның 5 п.; 319 номерлы карарның 1.5 п.; 100 номерлы карарның 1.5 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | 1. Субсидияләр формасында дәүләт ярдәмен күрсәтү өчен конкурс аша сайлап алуга заявканы кертү һәм мөрәҗәгать итүчегә заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр җибәрү (2 нче кушымта).<br>2. Субсидияләр формасында дәүләт ярдәмен күрсәтү өчен конкурс аша сайлап алуга заявканы кертүдән баш тарту һәм мөрәҗәгать итүчегә заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр җибәрү (3 нче кушымта). | 584 номерлы карарның 5.3 п; 1331 номерлы карарның 5.3 п.; 331 номерлы карарның 5.3 п.; 3178 номерлы карарның 20 п.; 319 номерлы карарның 5.3 п.; 100 номерлы карарның 5.3 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт | Субсидияләр формасында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен конкурс аша сайлап алуга заявканы кертү яки кертүдән | 584 номерлы карарның 5.3 п; 1331 номерлы карарның 5.3 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | баш тарту һәм мөрәҗәгать итүчегә заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр җибәрү заявка килгән вакыттан башлап 13 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | 331 номерлы карарның 5.3 п.; 3178 номерлы карарның 20 п.; 319 номерлы карарның 5.3 п.; 100 номерлы карарның 5.3 п. |
| 2.5. Закон яисә бүтән норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен, шулай ук дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. «Җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» һәм «Татарстан Республикасының социаль эшкуарлыгын үстерү» чараларын тормышка ашыру кысаларында башлап җибәрүче (заявка тапшыру вакытына теркәлү срогы бер елдан азрак булган) һәм гамәлдәге (заявка тапшыру вакытына теркәлү срогы бер елдан артык булган) эшкуарлык субъектлары тарафыннан тапшырыла торган документлар:<br>– шәхесне таныклаучы документ;<br>– вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш йөрткәндә);<br>– моңа вәкаләте булган затның имзасы һәм эшкуарлык субъектының (юридик затлар өчен) мөһере (мөһер булган очракта) белән таныкланган яки кулдан таныкланган (шәхси эшкуарлар өчен) гариза (1 нче кушымта).<br>Заявканы Портал аша тапшырган очракта, гариза гади электрон имза белән таныклана;<br>– шәхси эшкуарның яисә юридик зат җитәкчесенең | 584 номерлы карарның 4.1 п.; 1331 номерлы карарның 4.1 п.; 331 номерлы карарның 4.1 п.; 3178 номерлы карарның 15 п.; 319 номерлы карарның 4.1 п.; 100 номерлы карарның 4.1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | (физик затның) паспортының тутырылган битләре күчермәләре;<br>– заявка тапшыру датасына чагыштырмача соңгы хисап датасына бухгалтерия хисаплылыгы (бухгалтерия балансы һәм финанс нәтиҗәләре турында хисап) (салым органы тарафыннан хисаплылыкны кабул итү турында тамга белән яисә тиешле органның вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турында документларны кушып тапшырыла) яисә керемнәрне һәм чыгымнарны исәпкә алу кенәгәсе (402-ФЗ номерлы федераль закон буенча бухгалтериядә исәпкә алуны алып бармаучы эшкуарлык субъектлары өчен) (агымдагы хисап чорында теркәүгә алынган юридик затлардан (шәхси эшкуарлардан тыш));<br>– заявка тапшыру датасына чагыштырмача соңгы хисап датасына салым декларациясе (салым органы тарафыннан хисаплылыкны кабул итү турында тамга белән яисә тиешле органның вазыйфаи затының электрон имзасы белән имзаланган электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турында документларны кушып тапшырыла)(агымдагы хисап чорында теркәүгә алынган эшкуарлык субъектларыннан тыш);<br>– заявка тапшыру датасына чагыштырмача соңгы хисап датасына РФ ПФ Идарәсенең 83п номерлы карары белән расланган рәвештә теркәүгә алынган затлар турында белешмәләр (пенсия фонды органнарының хисаплылыкны кабул итү турында тамгасы белән яисә электрон санлы имза белән имзаланган электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турында документларны кушып тапшырыла)(агымдагы хисап чорында теркәүгә алынган | |

| | | |
|---|---|---|
| | эшкуарлык субъектларыннан тыш);<br>– гамәлгә кую документларының күчермәләре (юридик затлар өчен);<br>– заявка тапшыру датасына чагыштырмача соңгы хисап датасына узган календарь елы өчен ММ-3-25/174@ номерлы РФ ФСХ боерыгы белән расланган рәвеш буенча хезмәткәрләрнең уртача исемлек исәбе турында белешмәләр (салым органы тарафыннан хисаплылыкны кабул итү турында тамга белән яисә санлы электрон имза белән имзаланган электрон рәвештә кабул итү һәм тикшерү турында документларны кушып тапшырыла)(агымдагы хисап чорында теркәүгә алынган эшкуарлык субъектларыннан тыш);<br>– 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар белән расланган рәвеш буенча, мөрәҗәгать итүченең 584 номерлы карарда, 1331 номерлы карарда, 331 номерлы карарда, 3178 номерлы карарда, 319 номерлы карарда яисә 100 номерлы карарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында моңа вәкаләтле затның имзасы һәм эшкуарлык субъекты мөһере белән таныкланган (юридик затлар өчен) (Россия Федерациясе законнарында мөһер булдыру йөкләмәсе каралган очракта) яисә үз кулы белән тутырылган (шәхси эшкуарлар өчен) гарантия хаты.<br>2. Әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә, «Җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән | |

| | | |
|---|---|---|
| | чыгымнарын субсидияләү» чарасын тормышка ашыру кысаларында башлап җибәрүче эшкуарлык субъекты түбәндәгеләрне тапшыра:<br>– лизинг бирүче тарафыннан имзаланган, лизинг шартнамәсенең төп параметрларын күрсәтеп, субсидия бирелгән очракта лизинг шартнамәсе төзү турында гарантия хаты;<br>– күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар (күчемсез мөлкәт объектларына карата Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлгән булу очрагында мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны тапшырмаска хокуклы);<br>– проектны (булган очракта) үтәү өчен кирәкле булган, гамәлдәге контрактларның күчермәләре;<br>– лицензияләрнең һәм рөхсәтләрнең, патентларның, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә үткәрү-конструкторлык эшләре нәтиҗәләренең күчермәләре, эксперт бәяләмәләре һәм башкалар (булган очракта);<br>– 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар белән расланган рәвештә бизнес-проект паспорты;<br>– сәнәгать мәйданчыгының идарәче компаниясе белән сәнәгать мәйданчыгы территориясендә резидентның эшчәнлек алып баруы турында төзелгән килешү күчермәсе яисә идарәче компаниянең мөрәҗәгать итүченең сәнәгать мәйданчыгы резиденты булуын таныклаучы хаты (резидентлар реестрыннан өземтә)(сәнәгать мәйданчыклары резидентлары өчен);<br>– субсидия бирелгән очракта бер календарь елы эчендә | 584 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 1331 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 331 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 3178 номерлы карарның 53, 54, 55 п.; 319 номерлы карарның 7.6, 7.6.1, 7.6.2 п.; 100 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | резидентның сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җайланма урнаштыруы һәм аннан файдалануы турында гарантия хаты (сәнәгать мәйданчыклары резидентлары өчен);<br>– дәүләт мөлкәтенең аренда шартнамәсе күчермәсе (бизнес-инкубаторлар резидентлары өчен);<br>3. Әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә, «Җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасын тормышка ашыру кысаларында гамәлдәге эшкуарлык субъекты түбәндәгеләрне тапшыра:<br>– төп параметрларын күрсәтеп, төзелгән лизинг шартнамәсенең лизинг бирүче тарафыннан танықланган күчермәсе;<br>– җайланма сатып алу-сату шартнамәсе һәм эшкуарлык субъектының лизинг шартнамәсе буенча аванс күчерүе турында түләү турында банк тамгасы белән (булган очракта) түләү йөкләмәсенең лизинг бирүче таныклаган күчермәсе;<br>– күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар (күчемсез мөлкәт объектларына карата Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлгән булу очрагында мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны тапшырмаска хокуклы);<br>– проектны (булган очракта) үтәү өчен кирәкле булган, гамәлдәге контрактларның күчермәләре;<br>– лицензияләрнең һәм рөхсәтләрнең, патентларның, | 584 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 1331 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 331 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п.; 3178 номерлы карарның 53, 54, 55 п.; 319 номерлы карарның 7.6, 7.6.1, 7.6.2 п.; 100 номерлы карарның 7.7, 7.7.1, 7.7.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә үткәрү-конструкторлык эшләре нәтиҗәләренең күчермәләре, эксперт бәяләмәләре һәм башкалар (булган очракта);<br>– 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар белән расланган рәвештә бизнес-проект паспорты;<br>– сәнәгать мәйданчыгының идарәче компаниясе белән сәнәгать мәйданчыгы территориясендә резидентның эшчәнлек алып баруы турында төзелгән килешү күчермәсе яисә идарәче компаниянең мөрәҗәгать итүченең сәнәгать мәйданчыгы резиденты булуын таныклаучы хаты (резидентлар реестрыннан өземтә)(сәнәгать мәйданчыклары резидентлары өчен);<br>– субсидия бирелгән очракта бер календарь елы эчендә резидентның сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җайланма урнаштыруы һәм аннан файдалануы турында гарантия хаты (сәнәгать мәйданчыклары резидентлары өчен);<br>– дәүләт мөлкәтенең аренда шартнамәсе күчермәсе (бизнес-инкубаторлар резидентлары өчен).<br>4. Әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә, «Татарстан Республикасы социаль эшкуарлыгын үстерү» чарасын тормышка ашыру кысаларында башлап җибәрүче эшкуарлык субъекты түбәндәгеләрне тапшыра:<br>– эшкуарлык субъектының түбәндәге шартларның берсенә туры килүен раслый торган документларның күчермәләре:<br>а) түбәндә күрсәтелгән граждан категорияләренең уртача | 584 номерлы карарның 8.6 п.; 1331 номерлы карарның 8.6 п.; 331 номерлы карарның 8.6 п.; 3178 номерлы карарның 63 п.; 319 номерлы карарның 8.6 п.; 100 номерлы карарның 8.6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | исемлек саны эшкуарлык субъектлары хезмәткәрләре арасында кимендә 50 процент ә мондый хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү фондындагы өлеше – кимендә 25 процент тәшкил итә:<br>инвалидлар;<br>өлкән яшьтәге гражданнар (60 яшьтән өлкәнрәк ир-атлар һәм 55 яшьтән узган хатын-кызлар);<br>7 (җиде) яшенә кадәрге балалары булган хатын-кызлар;<br>ятимнәр;<br>балалар йортларыннан чыгарылучылар;<br>заявка тапшыру датасыннан алдагы 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затлар.<br>б) эшкуар түбәндәге эшчәнлек өлкәләрендә хезмәтләр күрсәтү (товарлар җитештерү, эшләр башкару) буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра:<br>– гражданнарның социаль яклanмаган төркемнәренә караучы затларның мәшгульлегенә һәм үзмәшгульлегенә булышлык күрсәтүне дә кертеп, һөнәри юнәлеш алуда һәм эшкә урнашуда булышлык күрсәтү;<br>– гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә караучы затларга һәм балалы гаиләләргә сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтү, балаларның һәм яшьләрнең түгәрәкләрендә, секцияләрендә, студияләрендә дәресләр уздыру;<br>– социаль туризм оештыру – гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә караучы затлар өчен экскурсия-танып белү турлары өлешендә генә;<br>– медицина техникасы, протез-ортопед эшләнмәләре, | |

| | | |
|---|---|---|
| | шулай ук, автомототранспортны да кертеп, бары тик инвалидлыкны профилактикалау яисә инвалидларны тернәкләндерү өчен генә файдаланырга мөмкин булган техник чараларны, материалларны җитештерү һәм (яисә) сату;<br>– мәдәният-мәгърифәт (музейлар, театрлар, мәктәп-студияләр, музыка учреждениеләре, иҗат остаханәләре) эшчәнлеген тәэмин итү;<br>– гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә караган затларга белем бирү хезмәтләре күрсәтү;<br>– гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә караган затларны, шулай ук 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат ителгән затларны һәм наркомания һәм эчкечелек белән интегүче затларны социаль-актив эшчәнлеккә җәлеп итүдә булышлык күрсәтү.<br>– күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар (күчемсез мөлкәт объектларына карата Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлгән булу очрагында мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны тапшырмаска хокуклы);<br>– проектны (булган очракта) үтәү өчен кирәкле булган, гамәлдәге контрактларның күчермәләре;<br>– лицензияләрнең һәм рөхсәтләрнең, патентларның, фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә үткәрү-конструкторлык эшләре нәтиҗәләренең күчермәләре, эксперт бәяләмәләре һәм башкалар (булган очракта);<br>– 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар белән расланган рәвештә бизнес-проект | |

| | | |
|---|---|---|
| | паспорты.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче учреждениегә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Заявка кәгазьдә яисә Порталда мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша электрон рәвештә («җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча заявка тапшыручы эшкуарлык субъектлары өчен) тапшырылырга мөмкин.<br>Заявка мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукы булган зат яисә ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче зат тарафыннан);<br>почта юлламасы белән.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче учреждениегә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган («Җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча заявка тапшыручы эшкуарлык субъектлары өчен). | 584 номерлы карарның 3.1.1 п.; 1331 номерлы карарның 3.1.1 п.; 331 номерлы карарның 3.1.1 п.; 3178 номерлы карарның 10 п.; 319 номерлы карарның 3.1.1 п.; 100 номерлы карарның 3.1.1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Заявка тапшырганда һәм шартнамә төзү максатларында тапшырыла торган барлык документлар, шул исәптән Портал аша тапшырыла торган документлар, төгәл бастырылган һәм барлык пунктлары буенча тутырылган булырга тиеш (белешмәләр булмаган очракта сызык куела). Чистартылган һәм төзәтелгән урыннар рөхсәт ителми, мөһер (мөһер булган очракта) белән беркетелгән һәм вәкаләтле зат имзасы (юридик затлар өчен) белән таныкланган яки кулдан (шәхси эшкуарлар өчен) таныкланган төзәтмәләрдән тыш. Кәгазьдә тапшырылган заявканың барлык битләре дә номерланган булырга тиеш. Кәгазьдә тапшырылган документларның күчермәләре моңа вәкаләтле затның имзасы белән һәм эшкуарлык субъектының мөһере белән таныкланган булырга тиеш (юридик затлар өчен) (мөһер булган очракта).<br>Портал аша скан аша чыгартылган күчермәләр рәвешендә тапшырылган документлар моңа вәкаләтле затның гади электрон имзасы белән имзаланган булырга тиеш.<br>Кәгазьдә тапшырылган заяка, заявканың икенче ягында гомуми битләр санын күрсәтеп, тегелгән һәм моңа вәкаләтле зат имзасы һәм эшкуарлык субъектының мөһере белән таныкланган булырга (юридик затлар өчен) (мөһер булган очракта) яки кулдан (шәхси эшкуарлар өчен) тутырылган булырга тиеш. | 584 номерлы карарның 3.2 п.; 1331 номерлы карарның 3.2 п.; 331 номерлы карарның 3.2 п.; 3178 номерлы карарның 11 п.; 319 номерлы карарның 3.2 п.; 100 номерлы карарның 3.2 п. |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән | Түбәндәге документлар ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша алына:<br>1) Эшкуарлык субъектын дәүләт теркәвенә алу турында документ (ОГРН);<br>2) Эшкуарлык субъектын салым исәбенә алу турында документ (ИНН); | 584 номерлы карарның 4.2 п.; 1331 номерлы карарның 4.2 п.; 331 номерлы карарның 4.2 п.; 3178 номерлы карарның 16 п.; 319 номерлы карарның 4.2 п.; 100 номерлы карарның 4.2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | 3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар турында законнар нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча эшкуарлык субъектының үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслаучы, заявка һәм документлар тапшырыла торган айның беренче көненә торышы буенча ММВ-7-8/20@ номерлы Россия ФСХ боерыгы белән расланган рәвештә салым органыннан бирелгән белешмә;<br>4) Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрыннан заявка тапшыру датасына кадәр 30 календарь көненнән иртәрәк булмаган чорда бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә;<br>5) Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан заявка тапшыру датасына кадәр 30 календарь көненнән иртәрәк булмаган чорда бирелгән һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган өземтә.<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган документларны, шул исәптән мөмкинлек булган очракта, электрон формада да тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Учреждение мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел: | |

| | | |
|---|---|---|
| | 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнарыннан, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| | турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәткәренең, вәкаләтле оешма хезмәткәренең дәүләт хезмәтләре күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән йә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда документаль расланган хаталы яки хокукка каршы килә торган гамәл кылуы (гамәл кылмавы) факты (билгеләре) ачыкланганда, бу хакта дәүләт хезмәте күрсәтүче органның яки дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган килештерү таләп ителгән дәүләт хакимияте органнары (җирле | Килештерү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Заявканың мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүгә хокуклы булмаган зат тарафыннан тапшырылуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә. | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | Чират көтүнең максималь чоры – 15 минуттан артмый. Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | 601 номерлы Президент указының 1 п. |
| 2.13. Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне, шул исәптән электрон рәвештә дә, теркәүгә алу вакыты | Документлар килгән көнне.<br>Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – учреждениенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә. | 584 номерлы карарның 5.2 п.;<br>1331 номерлы карарның 5.2 п.;<br>331 номерлы карарның 5.2 п.;<br>3178 номерлы карарның 19 п.;<br>319 номерлы карарның 5.2 п.;<br>100 номерлы карарның 5.2 п. |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр. | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлек итүенең саны һәм вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив технологияләрдән файдаланып. | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>– хезмәт күрсәтелә торган бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;<br>– дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>– белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның зарури санда булуы;<br>– мәгълүмат такталарында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;<br>– гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>– инвалидларга, биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, башка затлар белән тигез дәрәҗәдә аларга хезмәтләр алуга комачау итүче башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>учреждение белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга карата прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы. | 880 номерлы ТР МК карары белән расланган Тәртипнең 2.4 п.<br>601 номерлы Президент указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүченең учреждение белгечләре белән хезмәттәшлек итүе саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда, турыдан-туры – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча), ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә таныкланган кирәкле барлык документлар тапшырылган очракта, хезмәттәшлек итү зарурлыгы юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәргән очракта турыдан-туры бәйләнешкә керү таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең учреждение белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан учреждениегә телдән (шәхсән яисә телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать иткәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан | |

| | | |
|---|---|---|
| | (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре | «Җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү» чарасы буенча дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru) порталы аша гамәлгә ашырыла.<br>«Татарстан Республикасының социаль эшкуарлыгын үстерү» чарасы буенча дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү гамәлгә ашырылмый. | 584 номерлы карарның 3.1.1 п.; 1331 номерлы карарның 3.1.1 п.; 331 номерлы карарның 3.1.1 п.; 3178 номерлы карарның 10 п.; 319 номерлы карарның 3.1.1 п.; 100 номерлы карарның 3.1.1 п.<br>63-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 11 п. |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама.

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле заявканың составы, формасы һәм эчтәлеге буенча мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән заявканы рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) ярдәмендә электрон формада җибәрелгән белешмәләр бирү турында гарызнамәләр нигезендә документларны (белешмәләрне) яки алар белән тәэмин итүчеләрдән баш тарту турында хәбәр алу;

5) мөрәҗәгать итүченең һәм конкурста сайлап алуга катнашу өчен тапшырылган һәм документларның 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар таләпләренә җавап бирүен тикшерә;

6) гаризаны тикшерү нәтиҗәләре турында белдерүнамә төзү һәм аны учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзалау;

7) учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары имзалаган заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында белдерүнамәне учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыру;

8) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

9) дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтү;

10) техник хаталарны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелеге турында блок-схема әлеге административ регламентның 5 нче кушымтасында күрсәтелде.

3.2. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле заявканың составы, формасы һәм эчтәлеге буенча мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән заявканы рәсмиләштерү өлешендә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла. Процедураның озынлыгы шәхсән мөрәҗәгать иткәндә консультацияли башлау вакытыннан башлап 15 минуттан һәм телефон аша сөйләшә башлаган вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган заявканың составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча консультация, мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә ышанычлы заты аша документларны әлеге административ регламентның 2.5 пунктына туры китереп, учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыра. Документлар кәгазьдә яки электрон рәвештә Порталдан мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша (техник мөмкинлек булган очракта) тапшырылырга мөмкин.

Учреждениенең гомуми бүлегенең документларны кабул итүче белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели (документлар электрон рәвештә тапшырылган очраклардан тыш);

мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерә (ышанычнамә буенча эш йөртү очрагында)(документлар электрон рәвештә тапшырылган очраклардан тыш);

Заявка мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүгә хокуклы зат тарафыннан тапшырылган очракта, учреждениенең гомуми бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мәгълүмат системасында терки;

документларны кабул итү датасы турында тамгасы белән, мөрәҗәгать итүчегә керү номеры беркетелгән гариза күчермәсен тапшыра.

Әлеге административ регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта, учреждениенең гомуми бүлегенең документларны кабул итүче белгече, документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача рәвештә аңлатып, документларны мөрәҗәгать итүчегә кайтарып бирә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

15 минут эчендә заявканы һәм документларны кабул итү;

заявканы килгән көнендә теркәүгә алу.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат системасында теркәлгән гариза яки тапшырылган гаризаны кабул итү һәм теркәүдән баш тарту турында дәлилле нигезләмә.

3.4. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

Учреждениенең гомуми бүлек белгече ВЭХС ярдәмендә белешмәләр тапшыру турында гарызнамәләр җибәрә:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яисә Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

салым түләүче тарафыннан (җыемны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты тарафыннан) салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү йөкләмәләренең үтәлүе турында – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

узган календарь елы өчен хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны турында – Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан заявка тапшыру датасына булган торышында аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклар турында – Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте идарәсенә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: документлар (белешмәләр) бирү турындагы гарызнамәләр.

3.5. ВЭХС ярдәмендә белешмәләр бирү турында гарызнамәләр нигезендә документларны (белешмәләрне) яки белешмәләр белән тәэмин итүчеләрдән аларны бирүдән баш тарту турында хәбәр алу.

Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр, законнарда билгеләнгән чорда, ВЭХС аша килгән гарызнамәләр нигезендә сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә  дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документның һәм (яисә) мәгълүматның булмавы турында хәбәрләмә (алга таба – кире кагу турында хәбәрләмә) җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: әлеге документлар (белешмәләр) белән тәэмин итүче тарафыннан аларны бирү яки бирүдән баш тарту турында хәбәр.

3.6. Мөрәҗәгать итүченең һәм конкурста сайлап алуга катнашу өчен тапшырылган һәм документларның 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар таләпләренә җавап бирүен тикшерү.

Куркынычсызлык бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар таләпләренә җавап бирүен тикшерә;

тикшерү йомгаклары буенча бәяләмә төзи һәм бәяләмәне мәгълүмат системасында саклый.

Учреждениенең юридик бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яисә 100 номерлы карар таләпләренә җавап бирүен тикшерә;

тикшерү йомгаклары буенча бәяләмә төзи һәм бәяләмәне мәгълүмат системасында саклый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гарызнамәләргә җаваплар килгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: куркынычсызлык бүлеге белгеченең һәм юридик бүлек белгеченең мәгълүмат системасындагы бәяләмәсе.

3.7. Гаризаны тикшерү нәтиҗәләре турында белдерүнамә төзү һәм аны учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзалау.

Юридик бүлек белгече уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә мәгълүмат системасында куркынычсызлык бүлеге һәм юридик бүлек белгечләре бәяләмәләре нигезендә заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмә төзи һәм аны имза кую өчен учреждение җитәкчесенә яки аның урынбасарына җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган хәбәрләмә.

3.8. Учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары имзалаган заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында белдерүнамәне учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыру.

Юридик бүлек белгече учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары имзалаган заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмәне учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыра һәм мәгълүмат системасында хәбәрләмә текстын саклый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар хәбәрләмәгә учреждение җитәкчесе (учреждение җитәкчесенең урынбасары) кул куйган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында учреждениенең гомуми бүлегенә тапшырылган хәбәрләмә.

3.9. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү.

Учреждениенең гомуми бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә заявканы тикшерү турында хәбәрләмә тапшыра.

Хәбәрләмә мөрәҗәгать итүчегә электрон документ рәвешендә «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, заявкада күрсәтелгән электрон почтага җибәрелә. Документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Портал аша тапшырылган очракта, заявканы тикшерү турында хәбәрләмә мөрәҗәгать итүчегә Портал аша шәхси кабинетына җибәрелә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар аннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерү нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән хәбәрләмә.

3.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү күпфункцияле үзәктә һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.

3.11. Техник хаталарны төзәтү.

3.11.1. Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торучы документта техник хата ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче учреждениенең гомуми бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документ;

техник хата барлыгын дәлилли торган документлар.

Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе булып торучы документта күрсәтелгән белешмәләрдәге техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән тапшырыла яисә почта аша (шул исәптән электрон почта ярдәмендә) җибәрелә.

Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында

гаризаны кабул итә, гаризаны кушып тапшырылган документлары белән бергә теркәүгә ала һәм аларны учреждениенең юридик бүлегенә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән, учреждениенең юридик бүлегенә карау өчен юлланган гариза.

3.11.2. Учреждениенең юридик бүлек белгече документларны карый һәм төзәтелгән документны әлеге документны мөрәҗәгать итүчегә (вәкаләтле вәкиленә) шәхсән имзалатып, мөрәҗәгать итүчедән (вәкаләтле вәкиленнән) техник хатасы булган документның чын нөсхәсен алып калып тапшыру яки мөрәҗәгать итүченең адресына почта (электрон почта) аша учреждениегә техник хатасы булган документның чын нөсхәсен тапшырган очракта документ алу мөмкинлеге турында хат җибәрү өчен учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыра.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланган вакыттан башлап яисә җибәрелгән хата турында мәнфәгатьле теләсә кайсы заттан гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган (җибәрелгән) төзәтелгән документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны ачыклаудан һәм бетерүдән, дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә тикшерүләр уздырудан, учреждение вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүдән тора.

Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тору рәвешләре булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү. Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларга имза салу тора;

2) эш алып барылышына карата билгеләнгән тәртиптә уздырыла торган тикшерүләр;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү процедуралары үтәлешенә билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр уздыру.

Контроль тикшерүләр планлы (дәүләт хакимияте органының яртыеллык яисә еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин) һәм планнан тыш була. Тикшерүләр уздырылганда дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле (комплекслы тикшерүләр) яки мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә һәм карарлар кабул ителгәндә гамәлләр кылуны тикшереп тору максатларында учреждение җитәкчесенә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмәләр тапшырылырга мөмкин.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешенә агымдагы контрольлек учреждение җитәкчесе яисә куркынычсызлык бүлеге башлыгы тарафыннан тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.3. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеге учреждениенең структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә.

Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланганда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Учреждение җитәкчесе һәм аның урынбасары мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләрен вакытында карамаган өчен җаваплы була.

Учреждение җитәкчесе әлеге административ регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең вакытында һәм (яисә) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы була.

Вазыйфаи затлар дәүләт хезмәте күрсәтелгәндәге кабул ителә торган (гамәлгә ашырыла торган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә җаваплы була.

4.5. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә учреждение эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең) вазыйфаи затының (хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы учреждение хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә шикаять белдерү хокукына ия.

Шикаять учреждениенең югары торучы вазыйфаи затына тапшырыла, ә учреждение җитәкчесенең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителгән очракларда, – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына министр яки министрның беренче урынбасары исеменә.

Министрның (министр урынбасарының) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен аларның тапшырылуы Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәтен күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында караламган түләү таләп ителгәндә;

7) учреждение, учреждениедәге вазыйфаи зат яки аның хезмәткәрләре дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган документларда үзләре җибәргән хаталарны яки ялгышларны төзәтүдән  баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә,  2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача формада яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта аша җибәрелергә, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып учреждениенең электрон почтасына (crppmsp.rt.@tatar.ru), Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы рәсми сайты аша (http://mert.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) яисә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга яисә югары торучы органга (андый булган очракта) килгән шикаять аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә, ә дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең

билгеләнгән вакыты бозылган очракта, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән язу һәм басма хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктта күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә аның ихтыяры буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле

аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка 1 нче кушымта

Түбәндәге чара буенча субсидия алуга гариза

____________________________________________________________________

*(җайланмага лизингны үстерү: кече һәм урта эшкуарлык субъектларының җайланманың лизинг шартнамәсе («ЛИЗИНГ-ГРАНТ») буенча беренче кертемне (авансны) түләүгә киткән чыгымнарын субсидияләү, Татарстан Республикасының социаль эшкуарлыгын үстерү)*

| N п/п | Күрсәткечнең аталышы | Гариза бирүченең белешмәләре |
|---|---|---|
| 1. | Катнашучының тулы исеме | |
| 2. | ИНН | |
| 3. | КПП | |
| 4. | ОГРН | |
| 5. | ОКПО | |
| 6. | Проект тормышка ашырыла торган эшчәнлек төре (ОКВЭД буенча икътисадый эшчәнлек төре коды, шифрларын ачып) | |
| 7. | Юридик адресы | |
| 8. | Фактик адресы | |
| 9. | Дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 10. | Банк реквизитлары, ш.и. и-х/с, к/с, БИК | |
| 11. | Субсидия күчерелгән көннән башлап исәпләнүче ел нәтиҗәләре буенча хезмәткәрләрнең план исәбе (хезмәткәрләрнең заявка бирү вакытына булган исәбен исәпкә алып) | |
| 12. | Субсидия күчерелгән көннән башлап исәпләнүче ел нәтиҗәләре буенча бюджет системасының барлык дәрәҗә бюджетларына салым күчерүләрнең план күләме (иминият кертемнәрен һәм хезмәткәрләрнең НДФЛ түләүләрне дә кертеп) | |
| 13. | Продукция (товарлар, эшләр, хезмәтләр) сатудан план табышы | |
| 14. | Мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе (Ф.И.А., вазыйфа, элемтә реквизитлары) | |
| 15. | Баш бухгалтер (Ф.И.А., элемтә реквизитлары) | |
| 16. | Проект җитәкчесе (Ф.И.А., вазыйфа, элемтә реквизитлары) | |
| 17. | Җаваплы башкаручы (Ф.И.А., вазыйфа, элемтә реквизитлары) | |
| 18. | E-mail | |

Хәзергесе белән шунысын раслыйм:

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә:

– кече һәм урта эшкуарлык субъекты (кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм күрсәтү инфраструктурасы оешмасы) булып торам;

– «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 14 ст. 3 п. һәм 4 п. таләпләренә җавап бирәм.

*Барлык юллар да тутырылган булырга тиеш. Белешмәләр булмаганда сызык куела.*

Мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе

___________________ _______________________________

имза тулы имза

МУ

Хәзергесе белән «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм _________________________ тарафыннан әлеге заявкада һәм минем тарафтан тапшырылган теләсә нинди бүтән документларда булган минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

«Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм ______________________________ шәхси мәгълүматларны системага сала, туплый, саклый, тәгаенләштерә (яңарта, үзгәртә), файдалана, тарата (шул исәптән өченче затларга тапшыра), шәхси үзенчәлекләрен бетерә, файдаланылмаслык итә һәм юкка чыгара ала.

Мөрәҗәгать итүченең
җитәкчесе ___________________ _______________________________

имза тулы имза

МУ

Хәбәр итәбез, заявка формалаштырылган вакытка:

муниципаль берәмлек территориясендә эшчәнлек башкарам;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны һәм башка зарури түләүләрне түләүдә, шулай ук Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятләштерүенә иминият кертемнәре буенча үтәлмәгән йөкләмәләрем юк;

Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чаралар буенча элек алынган ярдәмгә бәйле рәвештә, шул исәптән акчадан файдалану һәм максатчан күрсәткечләргә ирешү турында хисаплылык тапшыру буенча үтәлмәгән йөкләмәләрем юк.

Тапшырылган мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Мөрәҗәгать итүченең
җитәкчесе _____________________ ______________________________

имза тулы имза

МУ

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка 2 нче кушымта

**Хәбәрләмә**

«Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм итү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе ________________________________________________________ тарафыннан

*(мөрәҗәгать итүченең атальшы)*

«________________________________________________________________________»

*(чараның атальшы)*

чарасында катнашу өчен тапшырылган конкурс заявкасын

______________________________________________________________________

*(_________№ ___ карар белән расланган субсидия бирү тәртибенең атальшы.)*

таләпләренә туры килүе предметы буенча тикшерү турында хәбәр итә.

Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча ____________________ заявкасы

*(мөрәҗәгать итүченең атальшы)*

конкурс комиссиясе утырышында катнашуга кертелә.

**Җитәкче** _____________/____________

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка 3 нче кушымта

**Хәбәрләмә**

«Татарстан Республикасы кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм итү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе «_____________________________________________» чарасы буенча

*(чараның аталышы)*

_____________________________________________ конкурс заявкасын

*(мөрәҗәгать итүченең аталышы)*

____________________________________________________________

*(_________№ ___ карар белән расланган субсидия бирү тәртибенең аталышы.)*

таләпләренә туры килүе предметы буенча тикшерү турында хәбәр итә.

Уздырылган тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге туры килмәүчәнлекләр ачыкланды:

1.________________________________________________________.

2.________________________________________________________.

Уздырылган тикшерү нәтиҗәсендә,_______________________________ ______________________________ конкурс комиссиясе утырышында катнашуга

*(мөрәҗәгать итүченең аталышы)*

кертелә.

**Җитәкче** _____________/____________

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка 4 нче кушымта

«ТР КУЭ ЯҮПТАҮ» ДКУ җитәкчесенә

______________________________________

кемнән________________________________

(ФИА/ оешма аталышы)

______________________________________

(яшәгән адресы/ урнашкан урыны)

**Техник хата төзәтү турында гариза**

20 елның «___»_____________ «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесеннән хәбәрләмә килде, аның текстында техник хата җибәрелгән.

Хәбәрләмәдә түбәндәгечә язылган:

________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________,

______________________________________________________________ бәйле рәвештә дөрес язу түбәндәгечә булырга тиеш:

________________________________________________________________________

______________________________________________________________________.

Бәян ителгәннәргә нигезләнеп түбәндәгеләр хакында сорыйм:

1. Техник хатаны төзәтүне;
2. Төзәтелгән хәбәрләмә бирүне.


Техник хатаны төзәтү өчен тапшырылган документлар һәм гаризада күрсәтелгән белешмәләр төгәл.

_________________ *(дата)*

_________________ *(имза)*

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка 5 нче кушымта

**Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге буенча блок-схема**



ВЭХС аша документларны (мәгълүматларны) тәэминатчылардан сорату – заявканы теркәү көнендә (гомуми бүлек)

↓

ВЭХС ярдәмендә электрон формада җибәрелгән белешмәләр бирү турында гарызнамәләр нигезендә документларны (белешмәләрне) яки алар белән тәэмин итүчеләрдән баш тарту турында хәбәр алу – сорату датасыннан башлап 5 эш көне (гомуми бүлек)

→

Конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга тапшырылган документларның һәм мөрәҗәгать итүченең 584 номерлы карар, 1331 номерлы карар, 331 номерлы карар, 3178 номерлы карар, 319 номерлы карар яки 100 номерлы карар таләпләренә туры килүен тикшерү – тәэминатчылардан гарызнамәләргә җавап алынган вакыттан башлап 5 эш көне (куркынычсызлык бүлеге һәм юридик бүлек)

↓

Заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмә төзү һәм аны учреждение җитәкчесеннән яки урынбасарыннан имзалату – алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне (юридик бүлек)

↓

Учреждение җитәкчесе яки аның урынбасары имзалаган заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмәне учреждениенең гомуми бүлегенә тапшыру – заявканы тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмә имзаланган көнне (юридик бүлек)

↓

Тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәрләмәне мөрәҗәгать итүчегә җибәрү – алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә (гомуми бүлек)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2017 елның 13 ноябрендәге 391 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 497 номерлы боерыгы редакциясендә) расланган Административ регламентка (белешмәлек) кушымта

**Татарстан Республикасы монопрофильле муниципаль берәмлекләренең (моношәһәрләренең) кече һәм урта эшкуарлык субъектларын субсидияләр формасында дәүләт ярдәме күрсәтү буенча конкурста сайлап алуда катнашуга кертү өчен кирәкле документларны карау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр**

1. «Татарстан Республикасының кече һәм урта эшкуарлыгына ярдәм күрсәтү һәм үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| **Вазыйфасы** | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Учреждение җитәкчесе | (843) 236-29-96 | Crppmsp.rt1@tatar.ru |
| Учреждение җитәкчесе урынбасары | (843) 236-04-83 | Crppmsp.rt1@tatar.ru |
| Учреждениенең юридик бүлек башлыгы | (843) 236-29-73 | Crppmsp.rt1@tatar.ru |
| Учреждениенең гомуми бүлеге башлыгы | (843) 293-03-58 | Crppmsp.rt1@tatar.ru |
| Учреждениенең куркынычсызлык бүлеге башлыгы | (843) 236-04-83 | Crppmsp.rt1@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| **Вазыйфасы** | Телефоны | электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | (843) 524–91–11 | me.rt@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары – Эшкуарлыкны һәм конкуренцияне үстерү департаменты директоры | (843) 524–91–12 | Rustem.Sibgatullin@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| **Вазыйфасы** | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Дәүләт мөлкәтенә идарә итү бүлегенең баш киңәшчесе | (843) 264–76–23 | Valiev.Ilnur@tatar.ru |